МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.12.2014 № 757

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 19 августында теркәлде, № 2857

Гражданнарның Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгына
кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау
тәртибен раслау турында

“Татарстан Республикасы гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 12 май, 2003 ел, № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында гражданнарның язмача һәм телдән мөрәҗәгатьләрен анализлауның бердәм тәртибен урнаштыру максатыннан боерык бирәм:

1. Гражданнарның Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) кергән мөрәҗәгатьләрен анализлауның кушымта итеп бирелүче тәртибен расларга.

2. Делопроизводство бүлеге начальнигын (С.А.Новикова) гражданнарның Министрлыкка кергән язмача рәвештәге, электрон хәбәрләр рәвешендәге, шулай ук Интернет-кабул итү бүлмәсе ярдәмендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләрен анализлау өчен җаваплы зат итеп билгеләргә.

3. Халык белән эшләү секторының әйдәп баручы киңәшчесен (Р.К.Гыйматдинова) гражданнарның Министрлыкка гражданнарны шәхсән кабул итү барышында һәм “Кайнар линия” телефоны буенча кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау өчен җаваплы зат итеп билгеләргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.12.2014 ел, № 757 боерыгына кушымта

**Гражданнарның Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнарның Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) кергән мөрәҗәгатьләрен анализлауның бу Тәртибе гражданнарның хокуклары һәм закон белән сакланылучы мәнфәгатьләре бозылуга китерә торган сәбәпләрне ачыклау, иҗтимагый фикерне өйрәнү, шулай ук Министрлыкта гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләүне камилләштерү максатыннан эшләнде.

Кабатланучы һәм күмәк шикаятьләргә китерүче сәбәпләрне бетерүгә аерым игътибар бирелергә тиеш.

1.2. Гражданнарның Министрлыкка кергән мөрәҗәгатьләренә анализ гражданнарның тиешле вакыт аралыгында кергән, шул исәптән язмача рәвештәге, электрон хәбәрләр рәвешендәге, шулай ук Интернет-кабул итү бүлмәсе ярдәмендә җибәрелгән, гражданнарны шәхсән кабул итү барышында һәм “Кайнар линия” телефоны буенча алынган мөрәҗәгатьләрен исәпкә алып ясала.

1.3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ мәгълүмат җыю, аны өйрәнү, гомумиләштерү, бәяләү һәм нәтиҗәләр әзерләү юлы белән ясала, бу вакытта кергән мөрәҗәгатьләрнең микъдар һәм сыйфат характеристикалары исәпкә алына, кабатланучы мөрәҗәгатьләр исәпкә алына, сорауларның төп тематикасы билгеләнә.

1.4. Анализның нәтиҗәләре министр каршындагы оператив киңәшмәләрдә карап тикшерелә һәм хезмәт эшчәнлеген планлаштырганда исәпкә алына, шулай ук гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләүнең нәтиҗәлелеген арттыруга булышлык итүче чаралар исемлеге төзелә.

## 2. Эшне оештыру

2.1. Һәр яртыеллык йомгаклары буенча ярты еллыкның ахыргы ае артыннан килүче айның 15 нче числосына кадәр гражданнарның Министрлыкка кергән мөрәҗәгатьләренә анализ ясау өчен җаваплы затлар гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерә.

2.2. Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләренә турыдан-туры анализ Электрон документ әйләнеше ведомствоара системасын файдаланып ясала.

2.3. Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләренә ясалган анализ нәтиҗәсендә елга ике тапкыр аналитик белешмә төзелә. Ул үз эченә гражданнарның мөрәҗәгатьләренә чагыштырма анализны (узган елгы чор белән чагыштырганда) алырга тиеш. Чагыштырма анализда кергән, башка адреска җибәрелгән һәм карап тикшерелгән язмача мөрәҗәгатьләр, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләр саны турында, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхсән кабул итү вакытында кабул ителгән гражданнар саны турында, гражданнарны шәхсән кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында һәм шәхсән күчмә кабул итү турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча күрелгән чаралар турында мәгълүмат, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм бүтән актлар (булганда) турында мәгълүмат булырга тиеш.

2.4. Аналитик белешмә яртыеллыкның ахыргы ае артыннан килүче айның 20 нче числосында Министрлыкның рәсми сайтына мәгълүмат технологияләре, автоматлаштырылган системаларга техник хезмәт күрсәтү һәм аларны эксплуатацияләү, Министрлыкның мәгълүмати куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлеге тарафыннан урнаштырыла.